**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН ГЛАВА ГАЙТАНКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» марта 2024 г № 3

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Полевая урамы 10 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Иске Авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Иске Аул торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 01.11.2023 ел № 3 карары.
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Иске Аул торак пунктында гражданнар Җыенының 01.11.2023 ел, №4 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Иске Аул торак пунктында теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Авыл торак пунктының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гәйтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева